Раслыйм:

«Сәләт» ТРЯИФ

Генераль директоры

Җ.Ш. Сөләйманов

_______________

“15” октябрь, 2018 ел.

«Әнвәр Хәйри укулары»
Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмә.

1.1. «Әнвәр Хәйри укулары» Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе (алга таба – Конференция) «Сәләт» Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге Дәүләт учреждениесе ярдәме белән, Татарстан Республикасы фәннәр академиясе, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасы милли китапханәсе, КФУ халыкара мөнәсәбәтләр, Алексеевск муниципаль районы администрациясе, Аксубай муниципаль районы администрациясе катнашында уздырыла.

1.2. Конференциядә катнашучыларның (укучыларның) фәнни эшләре конкурс эшләре буларак тәкъдим ителә һәм экспертлар советы тарафыннан бәяләнә.

1.3. Конференцияне оештыруны «Сәләт» Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый фонды үз өстенә ала.

1.4. Конференциянең максаты:
– Биләр каласы тарихын өйрәнгән, татар дөньясы тарихында зур эз калдырган галим, дус һәм Укытучы Әнвәр Хәйри исемен мәңгеләштерү;
- фәнни, иҗтимагый эшчәнлек алып барган галимнең фәнни-практик эшләренә карата укучыларда кызыксыну уяту;
- яшьләргә һәм мәктәп укучыларына тарихи-архиологик өлкәгә кагылышлы фәнни эшләрендә ярдәм итү.

1.5. Конференциянең бурычлары:

- Әнвәр Хәйринең фәнни-практик мирасын өйрәнү өчен мәйданчык булдыру;

- фәнни юнәлештә эшләүче укучыларның  бу өлкәдә сәләтләрен үстерү;

- иҗади һәм интеллектуаль ярыш аша укучыларны төрле фән өлкәләренә җәлеп итү, кызыксындыру, активлаштыру;

- ителлектуаль-иҗади эшчәнлекне популярлаштыру, укучылар арасында фундаменталь һәм гамәли фәннәргә кызыксыну тудыру;

- фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары галимнәре эшчәнлегенә карата кызыксыну уяту, укучыларны җәлеп итү;

- татар телен фундаменталь һәм гамәли фәннәр өлкәсендә актив куллану өчен мотивацион шартлар тудыру.

- Әнвәр Хәйринең эшчәнлеген яшьләрнең фәнни эшләрендә яктырту.

2. Фәнни юнәлешләр

2.1. Конференция түбәндәге юнәлешләрдә уздырыла:

2.1.1. «Биләр каласы: тарих, бүген һәм киләчәк».
2.1.2. «Әнвәр Хәйри мирасы».
2.1.3. «Мин яратам сине, туган җирем» (мисал өчен, мәктәбең тарихы, авылың тарихы, яшәгән урамың тарихы һ.б.ш.).
2.1.4. "Гаиләм тарихы" (мисал өчен, минем шәҗәрәм, гаиләм белән бәйле булган истәлекләр).
2.1.5 "Шәһре Бану – Шәрбән кыйссасы" - шул исемле Әнвәр Хайри китабы нигезендә язылган докладлар.

3. Конференция уздыру һәм эшләрне тапшыру тәртибе

3.1. Катнашучылар: Татарстан Республикасынннан, Рәсәй регионнарыннан һәм чит илләрдән  8-11-нче сыйныф укучылары һәм югары уку йортлары һәм көллиятләрдән 1-2 курс студентлары. Фәнни эшләр бер кеше тарафыннан да, күмәк эш (3 кеше) буларак та тәкъдим ителергә мөмкин. Проект фәнни җитәкче белән эшләнергә тиеш.

3.2. Конференциядә катнашу өчен 2018-нче елның 15-нчы октябрь – 25-нче ноябрь аралыгында selet.biz сайтында гариза калдырып,  fansar@selet.biz электрон адресына фәнни-тикшеренү эшенең тезисларын җибәрергә кирәк (һәрбер кәгазь бите аерым файл буларак беркетелергә һәм авторларның фамилияләре күрсәтелергә тиеш).

3.3. Конференциягә тапшырылган фәнни эшләр «Антиплагиат» системасында тикшерелә. Текстның авторлык (оригиналь) өлеше 65% - тан да ким булмаска тиеш. Шартлар үтәлмәгән очракта, фәнни эш эксперт советы әгъзалары тарафыннан тикшерелми.

3.4. Фәнни эшнең тезисларын 1-нче кушымтада күрсәтелгән таләпләр нигезендә тутырырга кирәк. Әдәбият исемлеген, шәрехләмәләрне күрсәтмичә тезисларда кыскача формада фәнни эшнең төгәл эчтәлеге билгеләнә.

3.5. Фәнни эшне тутыру таләпләре 2-нче кушымтада күрсәтелгән. Тикшеренү эше 25 биттән дә  артырга тиеш түгел (кушымталар өлеше тикшеренү эшенең битләр санына керми).

3.6. Тикшеренү эшләре Нигезләмә шартларына туры килмәгән очракта, Оештыру комитеты андый эшләрне Конкурска кабул итмәскә мөмкин.

3.7. Конкурсның Оештыру комитеты материалларның исемен һәм эчтәлеген тезислар җыентыгына бастырырга әзерләгән очракта, авторлар ризалыгы белән аларны төзәтергә, яисә тезизларны гомумән кертмәскә дә хокуклы.

3.8. Тикшеренү эшләренең электрон формасын, 4-нче кушымтада күрсәтелгәнчә тутырып, Оештыру комитетына PowerPoint форматында тапшырырга кирәк. Тапшырылган презентация эчтәлеге экспертлар советы әгъзалары тарафыннан бәяләнә.

4. Конференция уздыру һәм эшләрне тапшыру тәртибе

4.1. Конференцияне уздыру өчен Оештыру комитеты, фәнни тикшеренү эшләрен сайлау өчен Программа комитеты җаваплы. Оештыру һәм программа комитеты составын, шулай ук экспертлар советын «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры раслый.

4.2. Конференциянең уздыру вакыты һәм урыны.

| **Уздыру вакыты** | **Чаралар** | **Уздыру урыны** |
|---|---|---|
| **Читтән торып катнашу этабы** | | |
| 15-нчы октябрь, 2018 – 25-нче ноябрь, 2018 | Конференциядә катнашырга теләүчеләрнең электрон теркәлүе | www.selet.biz |
| 15-нчы октябрь, 2018 – 25-нче ноябрь, 2018 | Гаризалар, тикшерү эшләре, тезислар кабул итү (электрон теркәлүдән соң гына) | fansar@selet.biz |
| 15-нче ноябрь, 2018 – 25-нче ноябрь, 2018 | Конференциянең читтән торып катнашу этабы | Сәләт йорты (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) |
| 25-нче ноябрь, 2018 | Читтән торып катнашу этабының нәтиҗәләрен тәкъдим итү | www.selet.biz |
| **Экспертлар составы каршында эшне тәкъдим итү этабы** | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1-нче декабрь, 2018 | | |
| 10.00-11.00 | Конференциядә катнашучыларны теркәү, катнашучыларны урнаштыру | «Фэнсар» уку-укыту үзәге (Биләр каласы, Алексеевск районы) |
| 11.00-11.30 | Конференция ачылышы. Мөхтәрәм кунакларга сүз. | |
| 11.30-13.00 | Кунакларның түбәндәге темага чыгышы: «Әнвәр Хәйри – Шәхес, фән һәм җәмгать эшлеклесе» | |
| 13.00-14.00 | Көндезге аш | |
| 14.30-16.30 | Биләр каласының тарихи музеена сәяхәт | |
| 16.30-18.00 | Пленар утырыш:<br>1.Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең мөхбир-әгъзасы Хуҗин Фаяз Шәрип улы.<br><br>2. Биләр музей-тыюлыгы директоры Кутуев Әнәс Габдрахман улы. | |
| 18.00-19.00 | Кичке аш | |
| 20.00-22.00 | Әнвәр Хәйри иҗатына бәйле кичке чара | |
| 2-нче декабрь, 2018 | | |
| 08.30-09.00 | Уяну | |
| 09.00-10.00 | Иртәнге аш | |
| 10.00-13.00 | Конференциядә катнашучыларының чыгышы (аерым программа нигезендә) | |
| 13.00-14.00 | Көндезге аш | |
| 14.00-16.30 | Конференциядә катнашучыларының чыгышы (аерым программа нигезендә) | |
| 16.30-17.00 | Конференциянең ябылу тантанасы | |
| 17.00-18.00 | Катнашучыларны һәм кунакларны озату | |

4.3. Конференциядә экспертлар советы каршында эшне бер укучы гына (автор) тәкъдим итә.

4.4. Доклад Татарстан Республикасының дәүләт телләренең берсендә тәкъдим ителә ала – татарча яки русча. Әгәр доклад рус телендә сөйләнелә икән, эшне тәкъдим итү (презентация) татар телендә булырга тиеш.

4.5. Секцияләрдә чыгыш ясау өчен докладчыга 7-10 минут вакыт бирелә. Чыгыш ясау вакытында катнашучы кыскача, әмма тулы рәвештә үзенең тикшеренү эшенең эчтәләген сөйләп бирә. Плакатлар, таблицалар һәм санак (компьютер) кулланырга мөмкин.

4.6. Докладны тикшергәндә советы әгъзалары һәм барлык тыңлаучылар дә катнаша ала (5 минут).

4.7. Иң яхшы тикшеренү эшләре Конференциянең докладлар җыентыгында fansar.selet.biz сайтында бастырыла. Докладлар татар яки рус телендә була ала. Докладларга кыскача аңлатма бирелә, рус телендә язылган докладларга – татар телендә һәм киресенчә - татар телендә язылган докладларга – рус телендә.

5.1. Эшләрне бәяләү һәм тикшерү ике этапта уза:

5.1.1. I этап (читтән торып катнашу): конкурста катнашкан фәнни эшләрнең Оештыру комитеты тарафыннан барлык кагыйдәләр нигезендә эшләнгәнлеге тикшерелә, шуннан соң фәнни эшләр эксперт советына җибәрелә.

5.1.2. I этапта экспертлар советы тарафыннан иң яхшы эшләр сайлап алына. Катнашучыга 5 көннән дә калмый электрон почта аша яки башка юл белән конференциянең икенче этабына чакыру җибәрелә.

5.1.3. II этап: Конференциянең II этабында сайлап алынган иң яхшы фәнни эшләр конференциянең эспертлар составы каршында эшне тәкъдим итү этабында катнаша.

6. Бүләкләү тәртибе

6.1. Экспертлар советы киңәше нигезендә җиңүчеләргә һәм лауреатларга махсус дипломнар тапшырыла.

6.2. Катнашучылар сертификат белән бүләкләнә.

7. Оештыру комитеты белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат бирелә.

7.1. Оештыру комитеты адресы: Сәләт йорты, Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт. Электрон почта: fansar@selet.biz: Белешмә өчен телефон: +7 8432921600.

Кушымта 1
«Әнвәр Хәйри укулары»
Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе

Тезисларны тутыру һәм тәкъдим итү таләпләре

Тезисларда әдәбият исемлеген кертмичә, кыска формада тикшеренү эшенең төп эчтәлеге тасвирлана.

1. Схемаларның, рәсемнәрнең исемнәрен күрсәтү кирәк. Алар OS Windows форматында язылырга тиеш.

2. Бит форматы: А4.
3. Чикләр: өс – 2 см, ас – 2 см, уң – 2 см, сул – 2 см.
4. Хәреф язылышы: Times New Roman, кегль – 12.
5. Юл арасы: берле интервал.
6. Кызыл юлның башлану чиге: 1 см.
7. Текстны тигезләү: бит киңлеге буенча.
8. Чик контурлар китерелми.
9. Тезислар Times New Roman хәрефе белән бастырыла (12 пункт, калын) һәм үзәк буенча тигезләнә. Юл уртасында урнашкан бүлек башына нокта куелмый.
10. Доклад исеме астында: Авторның фамилиясе һәм исеме (тулысынча язылa) (11 пункт). Мәктәп, сыйныф, шәһәр.
12. Фәнни җитәкченең (укытучының) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме.
13. Түбәндә авторның уку оешмасының тулы исеме (курсив хәрефе белән).
14. Кызыл юлдан соң бер арадан тезислар материалы урнаштырыла.
15. Тезислар исеме, авторлар исемлеге, мәктәп һәм сыйныф, фәнни җитәкче исемнәре һәм киләсе текст берәр ара ераклык калдырып урнаштырыла. Мәктәп, сыйныф һәм фәнни җитәкче төрле юлдан билгеләнә.
16. Тезислар текстының күләме: А4 форматында 1 басма бит.

Кушымта 2<br>«Әнвәр Хәйри укулары»<br>Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе

Тикшеренү эшен тутыру һәм тәкъдим итү таләпләре.

I. Тикшеренү эше структурасы
1. Тикшеренү эше фәнни эшләр өчен кабул ителгән билгеле бер тәртиптә төзелә.
2. Структураның төп элементлары: баш бит, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, әдәбият исемлеге, кушымталар.
a) Баш бит тикшеренү эшенең беренче бите булып санала һәм үрнәккә карап тутырыла (Кушымта 3). Тикшеренү эшенең баш бите ике телдә: татар һәм рус телләрендә бастырыла (секцияләргә карамастан).
b) Баш биттән соң эчтәлек килә, эчтәлектә фәнни эшнең бүлекләре һәм битләре языла.
c) Фәнни эшнең кереш өлешендә сайлап алынган теманың актуальлеге, максаты, куелган бурычларның эчтәлеге, эзләнүнең объекты һәм предметы, методы, теоретик әһәмияте һәм килеп чыккан нәтиҗәләрнең кыйммәте күрсәтелә.
d) Фәнни эшнең төп өлешендә тикшеренү эшенең методикасы һәм техникасы күрсәтелә һәм нәтиҗәләре гомумиләштерелә. Эчтәлекне аңлатуга ярдәм иткән күрсәтмә материаллар кушымтада китерелә. Бүлекләр эчтәлеге фәнни тикшеренү темасына төгәл туры килергә һәм теманы ачып бирергә тиеш. Әлеге бүлекләр тикшерүченең материалны логик һәм кыскача тәкъдим итү сәләтен күрсәтә.
e) Фәнни тикшеренү эшенең йомгак өлешендә төп мәгънә һәм нәтиҗәләр күрсәтелә.
f) Тикшеренү эше ахырында әдәбият исемлеге күрсәтелә. Текстта фәнни чыганакларны күрсәтүче сылтамалар да булырга мөмкин (чыганакның сылтама номеры әдәбият исемлеге белән туры килергә тиеш)
g) Кушымтада ярдәмче, яки өстәмә материаллар куела. Шулай ук өстәмә җәдваллар, графиклар, рәсемнәр һ.б. күрсәтергә мөмкин.
II. Фәнни тикшеренү эшен тутыру тәртибе
1. Тикшеренү эшенең титул бите үрнәктә күрсәтелгәнчә төзелергә тиеш (Кушымта 1.3.).
2. Тикшеренү эше өзлексез тәртип белән бастырыла. Төрле текст өстәмәләре кертелми.
3. Форматлаштыру тәртибе:
a) Тикшеренү эшенең тексты Times New Roman хәрефе белән бастырыла (14-нче пункт), чикләре: сул – 3см (30 мм), уң – 1,5 см (15мм), өс – 2 см (20мм), ас – 2 см (20 мм). Текстны бит киңлеге буенча тигезләү зарури. Юл арасы 1,5 интервалында булырга тиеш. Чик контурлар китерелми.
b) Кызыл юл 1 см буш арадан башланырга тиеш.

c) Бүлек исеме белән текст арасында интервал 3-кә тигез. Бүлек исеме һәм параграф арасында да шул ук интервал саклана. Юл уртасында язылучы бүлек исеме ахырында нокта куелмый. Бүлек исеме астына сызу һәм юлдан-юлга күчерү тыела.
4. Фәнни-тикшеренү эше үтә күренмәле өске бит белән махсус папкага урнаштырыла (эшне файлларга урнаштыру тыела; файлларда бары тик фотосурәтләр, гербарийлар һ.б.ш. кушымта битләре генә булырга мөмкин). Программа белән диск аерым файлга урнаштырыла һәм беркетелә.

Кушымта 3
«Әнвәр Хәйри укулары»
Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе

Баш битне тутыру таләпләре.

«Әнвәр Хәйри укулары» Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе
Тема: “Туган җирем тарихы”
Тикшерү эше:

“Туып үскән авылым тарихы”
Иванов Кирилл, 11-нче сыйныф
Сидоров Максим, 10-нчы сыйныф
Катнашырга тәкъдим иткән оешма:

Экологик-биологик балалар үзәге, Казан шәһәре. Фәнни җитәкчеләр:
ө.б.у. I категория Макарова И.Н.,
б.ф.к., КФУ доценты Сидоров М.Ю.

Казан 2018

Кушымта 4
«Әнвәр Хәйри укулары»
Республикакүләм яшьләр фәнни-гамәли конференциясе

Электрон презентацияне әзерләү һәм тәкъдим итү таләпләре.

I. Электрон презентациянең структурасы

1. Тикшерену эшенең исеме, катнашырга тәкъдим иткән оешма исеме, докладчының һәм фәнни җитәкченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме.
2. Тикшерену эшенең төп максаты һәм бурычлары.
3. Тикшерену эшенең төп этаплары.
4. Йомгаклау (нәтиҗә).
5. Кулланылган чыганаклар исемлеге.
6. Тикшерену эшен язуда булышучыларга рәхмәт сүзе.
Слайдлар тәртибе доклад төзелешенә туры килергә тиеш.
II. Электрон презентацияне әзерләү

1. Әзерләү өчен бердәм стиль кулланыла (презентациягә туры килми торган стильләрдән баш тартыгыз).
2. Тикшерену эшенә туры килә торган төсләр кулланыла ( бер слайдта 3-тән дә артык төс булырга тиеш түгел: берсе фон өчен, баш бит һәм текст өчен). Фон һәм текст өчен контраст төсләр кулланыла.
3. Слайдта бары тик докладчының телдән сөйли торган төп сүзләре һәм җөмләләре булырга тиеш, ә текст язылмый.
4. Шрифт күләме: баш бит пункты 24 – 25, текст пункты 18 – 36. Курсив, калын һәм декоратив шрифт бары тик текстның мәгънәсен аерыр өчен генә кулланыла.
5. Мәгълүматны тапшырыр өчен слайдның төрле төрләре кулланыла ала: текст, җәдваллар, схемалар, графиклар, иллюстрацияләр. Барлык төрләр дә эчтәлектә күрсәтелергә тиеш.
6. Анимацияләр тыңлаучының игътибарын җәлеп итү өчен кулланыла. Төрле анимацион күренешләр фәнни эшнең эчтәлеген төгәлрәк күрсәтү өчен кулланыла ала, әмма алар мәгълүматнең эчтәлеген аңларга комачауламаска тиешләр.

III. Презентацияне тәкъдим итү таләпләре
1. Презентация файлы Microsoft PowerPoint 2007, OS Windows стандарт форматында булырга тиеш.
2. Электрон презентацияләр компакт диска яки Flash-җайланмасында OS Windows 7/8/10 системасы форматында тапшырылырга тиеш.